ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары тәшкил итә.»;

2) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3 статья. **Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге принциплары**

1. Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге гаделлек, кешелеклелек, законлылык, ачыклык, хаклык принципларына нигезләнә.
2. Вәкаләтле вәкил үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда нинди дә булса дәүләт органнарына һәм вазыйфаи затларга бәйсез була, шулай ук аларга хисап бирми.»;

3) 6 статьяда:
а) «Вәкаләтле вәкил» сүзләрен «1. Вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Вәкаләтле вәкил урынына кандидатның чит дәүләт гражданлыгы йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданынның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булырга тиеш түгел.»;

4) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Вәкаләтле вәкилнең вазыйфаларына керешүе ант иткән мизгеленнән санала.»;

5) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Вәкаләтле вәкил вазыйфасын биләүгә бәйле таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар**

1. Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) чит дәүләт гражданлыгын йә яшәүгә рөхсәтен яисә Россия Федерациясе гражданынның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алырга;

2) бер үк вакытта Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты булырга, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясе субъектларының башка дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны биләргә, шулай ук дәүләт хезмәтендә яисә муниципаль хезмәттә булырга;

3) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш, эшкуарлык эшчәнлеге белән үзенә яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашырга;

4) укыту, фәнни һәм бүтән төр иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле яисә түләүсез эш белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм бүтән төр иҗади эшчәнлек өчен түләү, әгәр башкасы Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчаларына финансланырга тиеш түгел;

5) сәяси партия яисә сәяси максатларны күз алдында тотып эшли торган башка иҗтимагый берләшмә әгъзасы булырга.

2. Вәкаләтле вәкилгә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга карата «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән башка чикләүләр, шулай ук бурычлар да кагыла.

3. Вәкаләтле вәкил үзенең статусы белән бергә башкарыла алмаган эшчәнлекне вазыйфага кергәнче кимендә 14 көн алда туктатырга, шулай ук үз

вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чорына сәяси партиядә әгъза булуын туктатып торырга бурычлы. Вәкаләтле вәкил билгеләнгән таләпләрне күрсәтелгән вакыт дәвамында үтәмәсә, аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

4. Вәкаләтле вәкил, үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуын барлыкка китерә торган нигезләр булганда, бу хакта кичекмәстән язмача Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә хәбәр итәргә бурычлы, шулай ук «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

5. Вәкаләтле вәкил үз вәкаләтләрен башкару срогы дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәргә тиеш.

6. Вәкаләтле вәкил федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.»;

6) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре туктатылу**

1. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре, әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә вәкаләтләр вакытыннан алда туктатылу очракларыннан тыш, яңа сайланган Вәкаләтле вәкил вазыйфаларына керешкән мизгелдән туктатыла.

2. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булса;

2) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалануга чикле сәләтле яисә хәбәрсез югка чыккан дип танылса йә вафат дип игълан ителсә;

3) аңа карата чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә керсә;

4) Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китсә;

5) Россия Федерациясе гражданлыгын югалтса, чит дәүләт гражданлыгын йә яшәүгә рөхсәтен алса яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алса.

3. Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән киңәшләшкәннән соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре шулай ук түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) вәкаләтләрен үз өстеннән төшерү турында язма рәвештә гариза бирсә;

2) медицина бәяләмәсе нигезендә билгеләнгән сәламәтлеге торышы буенча яисә башка сәбәпләр аркасында озак вакыт дәвамында (кимендә дүрт ай) үз бурычларын үти алмаса;

3) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $13^1$ статьясында каралган очракларда ышанычны югалтса;

4) «Россия Федерациясе субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2020 елның 18 мартындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законда

(алга таба – Федераль закон), башка федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән бүтән таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәсә.

4. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Вәкаләтле вәкил, аңа кадәрге Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан әлеге Законның 4 – 7 статьяларында билгеләнгән тәртиптә сайлап куелырга тиеш.»;

7) 13 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кеше һәм граждан хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан яклануына өстәмә гарантияләрне тәэмин итү максатларында Вәкаләтле вәкил Федераль закон нигезендә түбәндәгеләргә ярдәм итә:

1) кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга һәм торгызуга;

2) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлешендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын, муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерүгә;

3) кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, аларны яклау рәвешләре һәм ысуллары өлкәсендә халыкка хокукый белем бирүгә;

4) кеше хокуклары өлкәсендә регионара һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерүгә.»;

б) 2 өлештә «оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Вәкаләтле вәкилнең төп хокуклары**

1. Вәкаләтле вәкил үзенең төп бурычларын гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, Татарстан Республикасы территориясендәге мәҗбүри тоту урыннарына, хәрби частьларга үз эшчәнлегендәге мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тоткарлыксыз кереп йөрергә;

2) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар җитәкчеләреннән һәм башка вазыйфаи затларыннан кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен һәм

законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр, документлар, материаллар һәм башка мәгълүмат соратып алырга;

3) Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар эшчәнлегенә үз компетенциясе чикләрендә мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасының компетентлы дәүләт органнары, аларның вазыйфаи затлары, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, муниципаль хезмәткәрләр белән берлектә тикшерү үткәрергә;

4) дәүләт оешмаларын һәм фәнни оешмаларны шикаятьләрне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча эксперт тикшеренүләре уздыруга һәм бәяләмәләр әзерләүгә җәлеп итәргә;

5) Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар җитәкчеләренә һәм башка вазыйфаи затларына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрергә;

6) хөкем ителгәннәр һәм сак астына ябылган затлар белән икәүдән-икәү сөйләшергә, бу вакытта аларның әңгәмәләре җәза үтәтү учреждениесе яисә органы администрациясе яисә тикшерү изоляторы вәкиленә ишетелмәслек, ләкин үзләре күренерлек шартлар тудырылган булырга тиеш;

7) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

2. Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлегендәге мәсьәләләр буенча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары, шулай ук мәҗбүри тоту урыннары администрацияләре тарафыннан кичектергесез кабул ителү хокукыннан файдалана.

3. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында булырга, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшендә, шулай ук алар уздыра торган киңәшмәләрдә законнарда билгеләнгән тәртиптә катнашырга хокуклы.»;

9) 15 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле вәкил кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу турындагы мәгълүматны өйрәнү һәм анализлау, шикаятьләрне карау йомгакларын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә иҗтимагый тикшерүләр һәм иҗтимагый экспертиза уздыру турында тәкъдим белән чыгарга;

2) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу фактлары буенча парламент тыңлауларын уздыру турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәргә, шулай ук аларда турыдан-туры йә үз вәкиле аша катнашырга;

3) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу фактлары буенча парламент тикшерүен уздыру турында тәкъдим белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәргә, шулай ук парламент тикшерүен уздыру өчен парламент комиссиясе эшендә турыдан-туры йә үз вәкиле аша катнашырга.»;

10) $15^1$ статьяда:

а) 1 өлештә «Вәкаләтле» сүзен «1. Вәкаләтле» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасында төзелгән җәмәгать күзәтчелек комиссиясе Вәкаләтле вәкилгә ел саен, календарь ел тәмамланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокуклары тәэмин ителүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру йомгаклары буенча материаллар җибәрә.»;

11) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. **Вәкаләтле вәкилгә шикаять һәм башка мөрәҗәгатьләр тапшыру**

1. Россия Федерациясе гражданы, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат Вәкаләтле вәкилгә язмача яисә электрон документ рәвешендә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында телдән шикаять, тәкъдим яисә гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар мөрәҗәгатьләрен караганда «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә шикаятьләрнең Вәкаләтле вәкил тарафыннан карауга кабул ителүнең һәм карауның Федераль законда, әлеге Законда билгеләнгән үзенчәлекләрен, шул исәптән шикаятьләрне карау срокларын исәпкә алып кулланыла.

2. Гражданнар хокуклары һәм ирекләре бозылуга кагылышлы тәкъдим, гариза яисә башка мәгълүматны үз эченә алган мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) алганнан соң Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) мөрәҗәгатьне аның эчтәлеге буенча карарга;

2) гариза бирүчегә ул үз хокукларын һәм ирекләрен яклау өчен кулланырга хокуклы чаралар турында аңлатырга;

3) мөрәҗәгатьне компетенциясенә мөрәҗәгать карау кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка карау өчен җибәрергә.

3. Вәкаләтле вәкил исеменә бирелгән шикаять (алга таба – шикаять) дигәндә Россия Федерациясе гражданының, чит ил гражданының яисә гражданлыгы булмаган затның (алга таба – гариза бирүче), аның фикере буенча, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары яисә башка дәүләт органнары (Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан тыш), җирле үзидарә органнары, башка муниципаль органнар, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган, аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән оешмалар карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмаулары) аркасында бозылган (бозыла торган) хокукларын һәм ирекләрен яклау һәм торгызу турында, әгәр гариза бирүче тарафыннан элек бу карарларга яисә гамәлләргә (гамәл кылмауларга) суд тәртибендә йә административ тәртиптә шикаять

бирелеп, ул аның шикаяте буенча кабул ителгән карарлар белән килешмәсә, үтенече аңлашыла.

4. Мәҗбүри тоту урыннарындагы затлар тарафыннан Вәкаләтле вәкил исеменә язылган шикаятьләр һәм башка мөрәҗәгатьләр мәҗбүри тоту урыннары администрациясе тарафыннан укылырга һәм цензура үтәргә тиеш түгел һәм Вәкаләтле вәкилгә 24 сәгать эчендә җибәрелә.»;

12) 17 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шикаятьтә гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), почта һәм (яисә) электрон адресы, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган территориаль органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының яисә башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, башка муниципаль органнарның, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган, аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән оешмаларның, гариза бирүче фикере буенча, аның хокукларын һәм ирекләрен бозган (боза торган) карарларының яисә гамәлләренең (гамәл кылмавының) асылын бәян итү булырга тиеш. Шикаятькә шулай ук шикаятьнең нигезләнгән булуын раслый торган материаллар, тиешле карарларга яисә гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата суд тәртибендә яисә административ тәртиптә шикаять бирү белән бәйле документларның күчермәләрен дә кертеп, кушып бирелергә тиеш.»;

13) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Шикаять буенча карар кабул итү**

1. Шикаять кергән очракта Вәкаләтле вәкил:

1) шикаятьне, әгәр ул әлеге Законның 16 статьясындагы 3 өлешендә һәм 17 статьясындагы 1 өлешендә каралган таләпләргә туры килсә, карауга ала, бу хакта гариза бирүчегә хәбәр итә;

2) шикаятьне, әгәр ул әлеге Законның 16 статьясындагы 3 өлешендә һәм 17 статьясындагы 1 өлешендә каралган таләпләргә туры килмәсә, карауга алудан баш тарта, мондый очракта шикаятьне карауга алудан баш тартуның сәбәпләре күрсәтелергә тиеш.

2. Вәкаләтле вәкил шикаять теркәлгән көннән алып 15 көн эчендә шикаятьне карауга ала яисә аны карауга алудан баш тарта һәм бу хакта гариза бирүчегә хәбәр итә.»;

14) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Шикаятьне карау**

1. Вәкаләтле вәкил карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга шикаятьне карауга алуы турында хәбәр итә, шулай ук күрсәтелгән органнардан һәм

оешмалардан кергән шикаятьнең асылы буенча мәгълүмат соратырга һәм үз позициясен тулаем дәлилләүне тәкъдим итәргә хокуклы.

2. Шикаятьтә бәян ителгән шартларны тикшерү кирәк булган очракта Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) мөстәкыйль рәвештә яисә компетентлы дәүләт органнары, аларның вазыйфаи затлары һәм дәүләт хезмәткәрләре белән берлектә шикаятьтә бәян ителгән шартлар турында мәгълүмат җыярга, тикшерергә һәм аңа анализ ясарга;

2) дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга керергә;

3) мәҗбүри тоту урыннарына керү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендәге мәҗбүри тоту урыннарына тоткарлыксыз үтеп керергә;

4) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан шикаятьне карау өчен кирәкле белешмәләрне, документларны һәм материалларны соратып алырга, шулай ук аларның вазыйфаи затларыннан тиешле телдән аңлатмалар алырга;

5) карары законлы көченә кергән гражданлык яисә административ эш буенча материаллар белән танышу турындагы үтенечнамә белән судка мөрәҗәгать итәргә;

6) экспертлар җәлеп итәргә;

7) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка хокуклардан файдаланырга.

3. Федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының Вәкаләтле вәкил белән үзара эшчәнлеге тәртибе федераль башкарма хакимият органнары норматив хокукый актлары белән билгеләнә, моңа Вәкаләтле вәкилгә шикаятьне карау өчен кирәкле мәгълүмат алуда федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары тарафыннан аңа ярдәм итү тәртибе дә керә. Федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының Вәкаләтле вәкил белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында алар арасында тиешле шартнамәләр төзелергә мөмкин.

4. Шикаятьне, аерым алганда, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьне, карау барышында Татарстан Республикасы территориясендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылуларны бетерү буенча системалы чаралар кабул ителү кирәклеге Вәкаләтле вәкил тарафыннан ачыкланган очракта, Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ярдәм итүен һәм аның компетенциясенә караган чаралар күрүен сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5. Шикаятьне карау барышында җинаять җаваплылыгына тартылырга тиешле гамәл яисә административ хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, җинаять эше яисә административ хокук бозу турында эш кузгату турында карар кабул итү өчен Вәкаләтле вәкил, гариза бирүчегә бу хакта хәбәр итеп, булган материалларны тиешле дәүләт органнарына тапшыра.

6. Вәкаләтле вәкил шикаятьне карау барышында шикаять бирүченең һәм башка затларның шәхси тормышы турында аңа мәгълүм булган белешмәләрне әлеге затларның язма ризалыгыннан башка фаш итәргә хокуксыз.

7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Вәкаләтле вәкил тарафыннан, шикаятьтә язылган шартларны тикшерү тәмамланган көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә җибәрелергә тиеш.»;

15) 20 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

16) 21 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. **Вәкаләтле вәкилнең кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау һәм торгызу буенча чаралар кабул итүгә хокуклары**

Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу ихтималын тапкан дәүләт органына, муниципаль органга, оешмага, вазыйфаи затка күрсәтелгән хокукларны һәм ирекләрне торгызу буенча мөмкин булган һәм кирәкле чараларга карата үз тәкъдимнәрен язмача җибәрергә. Вәкаләтле вәкилдән тәкъдимнәр алган дәүләт органы, муниципаль орган, оешма, вазыйфаи зат 30 көн эчендә аларны карарга һәм күрелгән чаралар турында Вәкаләтле вәкилгә язмача хәбәр итәргә тиеш;

2) дәүләт органы, муниципаль орган, оешма, вазыйфаи зат, дәүләт хезмәткәре яисә муниципаль хезмәткәр карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бозылган кеше һәм граждан (шул исәптән чиксез затлар даирәсе) хокукларын һәм ирекләрен яклауга административ дәгъва гаризасы (дәгъва) белән судка мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау турындагы эш процессында шәхсән яисә үз вәкиле аша катнашырга;

3) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу ихтималы булган дәүләт органының, муниципаль органның, оешманың вазыйфаи затына карата дисциплинар эш кузгату һәм (яисә) җинаять эзәрлекләве турында мәсьәләне карау турында, шулай ук карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу ихтималы булган оешмага һәм (яисә) вазыйфаи затка карата административ хокук бозу турында эш буенча суд эше кузгату турында үтенечнамә белән тиешле компетентлы дәүләт органнарына яисә муниципаль органнарга мөрәҗәгать итәргә;

4) закон көченә кергән суд карарын кабат карау турындагы тиешле судка мөрәҗәгать итү хокукын прокурор тарафыннан, Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законнарында каралган очракларда, куллану максатларында, закон көченә кергән суд карарын тикшерү турындагы үтенечнамә белән прокуратурага мөрәҗәгать итәргә.»;

18) 24 статьяда:

а) исемдә «Татарстан Республикасы законнарын» сүзләрен «Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә, шулай ук аларны» сүзләрен «Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүдә, шулай ук аларны» сүзләренә алмаштырырга, «туры китерүгә ярдәм итү йөзеннән» сүзләрен «туры китерүдә катнашып» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы норматив хокукый актларда, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерә торган кимчелекләр яисә җитешсезлекләр ачыкланган очракта, Вәкаләтле вәкил аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәрне башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына җибәрергә хокуклы.»;

19) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья. **Вәкаләтле вәкилнең халыкка хокукый белем бирүдә катнашуы**

Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, аларны яклау рәвешләре һәм ысуллары өлкәсендә халыкка хокукый белем бирүдә катнашып, Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары булган массакүләм мәгълүмат чараларында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, аларны яклау рәвешләре һәм ысуллары турында мәгълүмат таратырга;

2) расланган чыгымнар сметасы чикләрендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре турында даими рәсми басма һәм башка басмалар чыгарырга;

3) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау проблемалары буенча фәнни-гамәли конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр», конкурслар, семинарлар, җыелышлар һәм башка гавами чаралар оештырырга һәм үткәрергә;

4) дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен өстәмә һөнәри программаларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

5) халыкка хокукый белем бирүнең башка рәвешләрен һәм ысулларын кулланырга.»;

20) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 статья. **Вәкаләтле вәкилнең еллык доклады**

Календарь ел тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт

Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына үз эшчәнлеге турында еллык доклад (алга таба – еллык доклад) җибәрә. Еллык доклад Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Вәкаләтле вәкил тарафыннан шәхсән тәкъдим ителә.»;

21) 27 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылуларның аерым мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына кеше һәм граждан хокукларын торгызу буенча тәкъдимнәр белән махсус докладлар җибәрергә мөмкин.»;

22) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28 статья. **Вәкаләтле вәкилнең докладларын бастырып чыгару**

1. Вәкаләтле вәкилнең еллык доклады, Вәкаләтле вәкилнең кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылуларның аерым мәсьәләләре буенча махсус докладлары Вәкаләтле вәкилнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

2. Вәкаләтле вәкилнең еллык доклады «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында рәсми басылып чыгарга тиеш. Махсус докладлар Вәкаләтле вәкил карары буенча басылып чыгарга мөмкин.»;

23) 30 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, әлеге органнарның һәм оешмаларның хезмәткәрләре:

1) Вәкаләтле вәкилгә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итәләр;

2) Вәкаләтле вәкил таләпләре буенча аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне, документларны, материалларны, башка мәгълүматны таләп алынган көннән алып 15 көннән дә соңга калмыйча, әгәр таләптә башка срок билгеләнмәгән булса, тапшыралар.»;

б) $1^1$ өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

24) 32 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.3, 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 28 июнендәге 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 6 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 6 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 25 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 һәм 9 пунктларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 2 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 27 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 17 пунктының «б» пунктчасын һәм 19 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 6 (II өлеш).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 04 июль
№ 35-ТРЗ